МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

25.05.2023 ел № 126

Казан шәһәре

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 317 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлеге җитәкчесенә дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторына әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 548 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 31 октябрендәге 548 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук төзелеше яки реконструкциясе ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль

районнар, шәһәр округлары) территориясендә урнашкан шәхси автомобиль юлларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 29 июлендәге 913 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 2 декабрендәге 1140 боерыгы белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 2 пунктын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 30 октябрендәге 548 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук төзелеше яки реконструкциясе ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территориясендә урнашкан шәхси автомобиль юлларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 24 июнендәге 239 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 16 декабрендәге 416 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләрнең 2 пунктын.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.В.Чукинга йөкләргә.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
___________________ № ______
боерыгы белән расланды

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территориясендә төзелә яки реконструкцияләнә торган шәхси автомобиль юлларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып төзүче яки техник заказчы функцияләрен башкара торган, язмача яки электрон формада гариза белән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән физик яки юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда катнаша.

Дәүләт хезмәте күрсәтү мөрәҗәгать итүче ихтыяры буенча теләсә кайсы КФҮ аша башкарыла: физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен – яшәү урынына яки тору урынына бәйсез рәвештә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарлар КФҮ әлеге Регламентның 2.7 пункты таләпләре нигезендә кабул ителә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт (Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны төзүгә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы белән расланган форма буенча);

2) объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар;

3) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар;

4) объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар;

5) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын бирү (бирүдән баш тарту).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында карар, объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында мәгълүмат (карарны электрон имза белән имзалаган очракта).

2.3.3. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту, объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карарның реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында мәгълүмат (карарны электрон имза белән имзалаган очракта).

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон

документ формасында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә кәгазьдә алу өчен мөрәҗәгать итүче белдерүдә үзенә кирәкле ысулны сайлый.

2.3.5. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлыкта яки күпфункцияле үзәктә кәгазьдә бастырып чыгарылган, мөһер һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәк хезмәткәренең имзасы белән таныкланган электрон документ формасында бирелә.

2.3.6. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта күренә торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы беркетелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Министрлыкта теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек чорда, шулай ук күпфункцияле үзәк Регламентында каралган чорны исәпкә алып күрсәтелә.

2.4.4. Объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү яки әлеге рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, объектны файдалануга кертүгә элегрәк бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны теркәгәннән соң биш эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә кабул ителә.

2.4.5. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү (бирүдән баш тарту) процедурасын гамәлгә ашыру вакыты Министрлыкта объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү (бирүдән баш тарту) турындагы гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне тәшкил итә.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ формасында да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлыкның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар;

2) төзүгә рөхсәт;

3) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) турында акт (мондый тоташтыру (технологик ялгау) проект документларында каралган очракта);

4) дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары таләпләренә (эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне дә исәпкә алып) туры килүе турындагы бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырылу каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе;

5) капиталь төзелеш объектының «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әзерләнгән техник планы;

6) «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты, әлеге объектка реставрация, консервация уздырганда, аны ремонтлаганда һәм заманча файдалану өчен яраклаштырган очракта.

2.6.2. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итүче объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә:

кәгазь документ формасында (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә);

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, Регламентның 2.6.5 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

Мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә). Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен раслый торган документ.

Гаризага әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 5, 6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар теркәлә.

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 1 һәм 3 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр әлеге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булмаган булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә.

2.6.3. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гаризаны, әлеге рөхсәтне алу өчен кирәкле документларны, капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны, әлеге рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен кирәкле документларны кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм барышы турында мәгълүмат җиткерү һәм әлеге рөхсәтне бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла ала:

1) шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән турыдан-туры Министрлык тарафыннан яисә почта аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрү юлы белән;

2) күпфункцияле үзәк белән Министрлык арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пункты таләпләренә туры килә торган электрон документлар рәвешендә;

3) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, электрон формада.

2.6.4. Гаризаны ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле зат тарафыннан рәсмиләштергән очракта, паспорт (шәхесне таныклый торган башка документ), нотариаль таныкланган ышаныч кәгазе яки законнар нигезендә нотариаль таныкланган ышаныч кәгазенә тигезләштерелә торган ышаныч кәгазе күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризага теркәп тапшырыла торган документларның күчермәләре нотариаль расланырга мөмкин. Нотариаль таныкланган күчермәләр булмаганда, тигез дәрәҗәдә түбәндәгеләр кабул ителергә тиеш:

дөреслеге җитәкченең яки моңа вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән таныкланган документларның күчермәләре;

документның төп нөсхәсен күрсәтү шарты белән, таныкланмаган күчермәләр. Шул ук вакытта документның күчермәсе документларны кабул итүче зат тарафыннан төп нөсхәсе белән чагыштырыла.

2.6.5. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика

порталы аша җибәргән очракта, физик затлар һшм шәхси эшкуарлар гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Министрлык тарафыннан, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 1 һәм 4 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), әгәр мөрәҗәгать итүче (төзүче оешма) аларны мөстәкыйль тапшырмаса, әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан соратып алына.

җир участогына хокук билгеләүче документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, гавами сервитут билгеләү турында карар – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе);

дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары таләпләренә (эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне дә исәпкә алып) туры килүе турындагы бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырылу каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе – Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге

инспекциясеннән, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсеннән (Ростехнадзор).

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән документ Министрлык карамагында тора.

2.6.7. Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне), мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында яки күпфункцияле үзәккә кәгазь чыганакта тапшыра ала.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.8. Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән документта һәм бәяләмәдә капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре составына кертелгән күрсәткечләрнең норматив күрсәткечләре турында һәм төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектына карата үткәрелгән тикшеренүләр, үлчәүләр, экспертизалар, сынаулар нәтиҗәсендә ачыкланган мондый күрсәткечләрнең фактик әһәмиятләре турында мәгълүмат, шулай ук мондый объектның энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителү таләпләренә туры килүен билгеләү өчен нигез булган башка мәгълүматлар була.

2.6.9. Әгәр объектны төзү, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү этабына карата файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән булса, 2.6.1 пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына караган өлештә рәсмиләштерелә. Әлеге очракта объектны төзү этабына, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә карата файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризада объектны төзү этабына, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә карата (булган очракта) элек бирелгән рөхсәтләр турында мәгълүматлар күрсәтелә.

2.6.10. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгәннән соң хокукларны дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм (яки) дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру туктатып торылуга (хокукларны дәүләт кадастр исәбенә алудан һәм (яки) дәүләт теркәвенә алудан баш тартуга) бәйле рәвештә, мондый туктатып тору (баш тарту) сәбәпләрен юкка чыгару өчен, капиталь төзелеш объектының эчтәлеге капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүне таләп итә торган техник планы әзерләнгән булса, төзүче объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән органга яисә оешмага әлеге рөхсәткә (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы) үзгәрешләр кертү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

моңа кадәр объектны файдалануга кертүгә бирелгән, үзгәрешләр кертү таләп ителә торган рөхсәт;

капиталь төзелеш объектының эчтәлеге объектны файдалануга кертүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүне таләп итә торган техник планы.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган башка

документларны да тапшыра, әгәр бу пункт нигезендә мондый документларга капиталь төзелеш объектының техник планын әзерләүгә бәйле үзгәрешләр кертелгән булса.

2.6.11. Әгәр объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгәннән соң, техник хата ачыклана икән, мөрәҗәгать итүче объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән органга яки оешмага техник хатаны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

моңа кадәр объектны файдалануга кертүгә бирелгән, техник хатасы булган рөхсәт;

техник хата барлыгын дәлилли торган документлар.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында, кырларның тулысынча тутырылмавы;

2) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

3) электрон формадагы гариза һәм башка документлар 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып, электрон имза белән имзаланган очракта.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне, мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына һәм (яки) күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны тапшырмау;

2) капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү буенча төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын тапшыру датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки, линияле объектны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне таләп итми торган линияле объектны төзү, реконструкцияләү очракларыннан тыш) таләпләренә, урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән

таләпләргә җавап бирмәве;

3) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;

4) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының проект документлары параметрларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;

5) капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгән датага җир законнары һәм Россия Федерациясенең башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә җавап бирмәве, күрсәтелгән чикләмәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендәге 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән территориядән файдалану буенча махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки әлеге зонаны үзгәртү турында карарда каралган һәм урнаштырылуына бәйле рәвештә территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнгән яки үзгәртелгән төзелә, реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объекты файдалануга кертелмәгән очраклардан тыш.

2.8.3. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты сорап мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү хокукына ия булган затлар даирәсенә туры килмәве;

2) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын бирү турындагы гаризада объектны файдалануга кертүгә бирелгән рөхсәт реквизитларының булмавы;

3) объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт дубликаты бирү турындагы гаризада күрсәтелгән объектны файдалануга кертүгә рөхсәтнең Министрлык тарафыннан бирелмәгән булуы.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына яки күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен

теркәүгә алу чоры.

2.11.1. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталда, Республика порталында үзенең шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.11.3. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза вазыйфаи инструкция нигезендә гариза гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыручы күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан алынган көнендә теркәлә.

Гаризаны һәм теркәлүче документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.

Күпфункцияле үзәк аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Министрлыкта алынган көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм анын чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль һәм текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә

сукырларны озата йөри торган этне кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык яки күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итүе түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алган очракта, бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара бәйләнешкә керү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, Министрлыктан, күпфункцияле үзәктән алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.14.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт

хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү;

7) техник хатаны төзәтү;

8) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү (бирүдән баш тарту).

3.4. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

3.4.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлыкның автомобиль юллары бүлеге белгече (алга таба – бүлек).

3.4.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең рәсми http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.4.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Министрлыкның рәсми сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.5. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау

Мөрәҗәгать итүче гаризаны шәхсән үзе, ышанычлы заты аша, почта, электрон почта буенча, Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы, күпфункцияле үзәк аша тапшыра ала.

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны КФҮ аша яки КФҮ ерактагы эш урыны аша кабул итү.

3.5.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән КФҮ мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.5.1.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган хезмәткәре күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: кабул ителгән һәм теркәлгән документлар пакеты белән гариза.

3.5.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшыра.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.5.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гарызига формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гаризада электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.5.3. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

3.5.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

3.5.3.2. Мөрәҗәгать итүче гариза белән министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели, мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документларны тапшырган затның вәкаләтләрен тикшерә, документларның әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннарның һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннарының булу-булмавын) туры килү-килмәвен тикшерә;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзалаганнан соң, имзаланган гаризаны сканер аша уздыра;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки сканер аша уздырылган документларның электрон рәвешләрен кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара.

алынган документларны Министрлык Бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән вазыйфаи затларына (алга таба – Бүлек белгечләре) карау өчен тапшыра.

Документлар карау өчен алынганнан соң, Бүлек белгече:

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон рәвешләренең комплектлылыгын, укылышлылыгын тикшерә; Бердәм порталга, Республика порталына керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар тапшырылган булса);

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга белдерелә торган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәнең) атамасы турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш), килештерү өчен билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын Министрлыкта Эшчәнлек башкару күрсәтмәсендә каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүче сайлаган ысул белән җибәрелә:

1) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә яки 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада;

3) Министрлыкка шәхсән барган очракта кәгазь чыганакларда;

4) гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән;

5) Министрлыкның электрон почтасы аша.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаса, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.5.3.3. Әлеге Регламентның 3.5.3.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.5.3.4. Әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карап тикшерүгә кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.3.5. Бүлек белгечләре объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналын (алга таба – Журнал) алып бара.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы);

мөрәҗәгать итүченең аталышы;

документларны кабул иткән Министрлыкның структур бүлекчәсе вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны;

объектны файдалануга кертүгә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә объектны файдалануга кертүгә рөхсәтне (объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тартуны) тапшыру датасы яисә почта аша җибәрү датасы;

объектны файдалануга кертүгә рөхсәтне (документларны теркәп, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы

искәрмә.

Журнал кулдан язып һәм электрон формаларда, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы рәвештә алып барыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Журналдагы язу.

3.6. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.6.1. Министрлыкның ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган

документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе) җибәрелә;

дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары таләпләренә (эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне дә исәпкә алып) туры килүе турындагы бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырылу каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе.

Рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсенә (Ростехнадзор) җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.6.2. Әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.6.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып

булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавапны әзерләү һәм җибәрү вакыты – ведомствоара рәсми мөрәҗәгать килгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

3.6.4. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә баш тарту турында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган белдерү.

3.6.5. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр алынган көнне үтәлә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Министрлыкка җибәрелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту турында белдерү.

3.6.6. Әлеге Регламентның 3.6.1, 3.6.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны теркәгән вакыттан башлап, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар җыелмасын карый;

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча объектны файдалануга кертүгә рөхсәт проекты әзерли;

әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт проекты.

3.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт проектын (алга таба – документларның проектлары) килештерү һәм имзалау дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, бүлек җитәкчесе, идарә җитәкчесе, министр урынбасары тарафыннан башкарыла.

Документларның әзерләнгән, кисәтүләре булган проектлары эшләп бетерү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затка кире кайтарыла. Кисәтүләре бетерелгәннән соң, документларның проектлары янә килештерү һәм имзалау өчен җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.8.1. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы белешмәләрне терки һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар кертелә торган ярдәмче системасына һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасына кертә (бу абзац таләбе 2023 елның 1 сентябренә кадәр гамәлдә була);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып баруда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында белешмәләрне «Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертә, моңа төзелешкә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган очраклар керми (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 сентябреннән гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм Министрлыкта яисә күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар, дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ имзаланганнан соң, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.8.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә. Кәгазьдәге электрон документ нөсхәсен ясауга нигез булган электрон документ нөсхәсен алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздырганда яки электрон почта буенча җибәргәндә, мондый электрон документ нөсхәсенең кәгазьдәге электрон документ нөсхәсенә тәңгәллеге көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирүне күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәве, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Бердәм порталны, Республика

порталын кулланып җибәрү (бирү).

3.8.2.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта тапшыра. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне, Министрлыкның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын теркәү, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту).

3.9. Объектны файдалануга кертүгә элегрәк бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү

3.9.1. Бүлек белгече объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны кабул итә, кушымтадагы документлар белән гаризаны терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кигән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.2. Бүлек белгече документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәтне алып калып, объектны файдалануга кертүгә кертелгән үзгәрешләре белән рөхсәтне мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) кул куйдыртып шәхсән тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәтне Бүлеккә тапшырган очракта, документ алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әгәр объектны файдалануга кертүгә рөхсәт мөрәҗәгать итүчегә элек электрон формада бирелгән булса, Бүлек белгече төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән кул куйдыртып тапшыра яисә, гаризада күрсәтелгән булса, электрон документ формасында бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) объектны файдалануга кертүгә кертелгән үзгәрешләре белән рөхсәт яки объектны файдалануга кертүгә элегрәк бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар.

3.10. Техник хата төзәтү

3.10.1. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә,

теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кигән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.10.2. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Техник хатасы булган документ мөрәҗәгать итүчегә электрон формада бирелгән булса, Бүлек белгече төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып тапшыра яисә, бу хакта гаризада күрсәтелгән булса, электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

3.11. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү (бирүдән баш тарту)

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм бирү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дубликат бирү өчен кирәкле документлар исемлеге, дубликат бирү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.11.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан Министрлыкка шәхсән, почта аша (шул исәптән электрон почта аша) яки Бердәм портал, Республика порталы яки күпфункцияле үзәк аша тапшырыла.

3.11.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы булган

вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар гаризаны теркәү датасыннан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.11.3. Мөрәҗәгать итүче объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын алу өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын

яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хатын кәгазьдәге электрон документ формасында тапшыра. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә. Кәгазьдәге электрон документ нөсхәсен ясауга нигез булган электрон документ нөсхәсен алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздырганда яки электрон почта буенча җибәргәндә, мондый электрон документ нөсхәсенең кәгазьдәге электрон документ нөсхәсенә тәңгәллеге көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан таныклана.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын бирү яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хатын Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәү, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хаты.

3.11.4. Мөрәҗәгать итүче объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын алу өчен Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать иткән очракта, объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хаты, Министрлыкның вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, автомат рәвештә электрон үрнәк рәвешендә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хаты Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: Бердәм порталдан, Республика порталынннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хатын җибәрү (бирү).

3.11.5. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгат иткән очракта, документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы булган вазыйфаи зат мөрәҗәгать Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликаты бирүдән баш тарту хатын тапшыра. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән берлектә, алына һәм куела торган мәгълүмат чыганагына яздыру юлы белән яки электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына җибәрү юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелә.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә объектны

файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт дубликатын бирүдән баш тарту хатын тапшыру тора.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге буенча агымдагы контрольлек тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат, Төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Көндәлек тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контроль тәртибе һәм формалары

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләр үткәрү ешлыгы планлы характерда (Министрлыкның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерда була.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша

торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә монополиягә каршы органга белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15' статьясында күрсәтелгән гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки

мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын, Бердәм порталны, Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр. Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә мөмкин булган элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) яисә почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу

яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.9. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

кемгә: Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
кемнән: ________________________________
(төзелешне, капиталь ремонтны яки реконструкцияне гамәлгә ашыручы төзүче оешма – юридик затның исеме;
________________________________________
ИНН;
юридик һәм почта адреслары; электрон почта адресы;
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);
________________________________________
телефон; банк реквизитлары
________________________________________
(банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гариза

Автомобиль юлын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүегез турында үтенәм

______________________________________________________________________________
(аталышы)

түбәндәге адрестагы җир кишәрлегендә: ____________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Төзелеш (реконструкция) төзелешкә бирелгән _______ елның «___» _______________ № ________ рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырылды.

Җирдән файдалану хокукы беркетелгән ______________________________________
(документ исеме)
_____________________________________________ _____ елның «____»_________ № __________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзелешне (реконструкцияне) финанслау гамәлгә ашырылды: ______________________________
______________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның «___»_____________ № _____ килешү нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылды
______________________________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юрилик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА,
______________________________________________________________________________
телефон номеры, электрон почта адресы
______________________________________________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән_______________________________________
______________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)
______________________________________________________________________________

«____»__________________ ел, №______________________

Эшләрне башкаручы итеп «___»___________ ел,
№____________ боерык нигезендә _______________________________________________ билгеләнгән.
(вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме)

______________________ махсус белеме һәм эш стажы бар
(югары, урта)

төзелештә ______________________________________ел
Төзелеш контроле «___»________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә
башкарылды ____________________________________________________________________

________________________________________________________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юрилик һәм почта адреслары, житәкченең ФИА,
________________________________________________________________________________________________________
телефон номеры, банк реквизитлары
________________________________________________________________________________ (банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК)
заказчы (төзүче) функцияләрен үтәү хокукы беркетелгән___________________________________________________
________________________________________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)
№ ____________ «____»___________________ ел.
Төзелгән (реконструкцияләнә торган) автомобиль юлына милек хокукын дәүләт теркәвенә алуга ризалык белдерәм. (_____________________________________________________________________________________)
(хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүмат)

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында _____________________________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.
(вәкаләтле орган атамасы)

______________________ ____________________ ________________________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

«___»_____________20____ ел.

М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

кемгә: Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына

кемнән: ______________________________

(төзүче – юридик затның исеме, төзелешне, капиталь ремонтны яки реконструкцияне башкарырга планлаштыручы;

______________________________

ИНН; юридик һәм почта адреслары; Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

______________________________

телефон; банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә элек бирелгән 20___ елның «____»_____________ рөхсәткә үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

№ ____________________ ______________________________________________________

(объектның атамасы)

түбәндәге адрестагы җир кишәрлегендә: _____________________________________________

(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

Төзелеш (реконструкция) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырылды

_______________________________________________ _____ елның «____»_________ № _______

(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелгән _____________________________________________

__________________________________________________ _____ елның «____»_________ № _______

(документ исеме)

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Капиталь төзелеш объектын төзүне (реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны) төзүче тарафыннан финанслау гамәлгә ашырылды _______________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр 20___ елның «___»______________ № _____ килешү нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылды.

__________________________________________________________________________________

(оешма атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА, телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/сч, к/сч, БИК)

__________________________________________________________________________________

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән _______________________________________________

__________________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

«____»___________________ ел, №______________________

Эшләрне башкаручы итеп «___»___________ ел,

№ _________ билгеләнгән ___________________________________ булган _________________________ махсус

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме) (югары, урта)

белемгә ия һәм төзелештәге эшләү стажы ___ ел.

Төзелеш контроле «___»________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә

башкарылды _____________________________________________________________

(оешма атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА (соңгысы булган очракта), телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/сч, к/сч, БИК)

______________________________________________________________________________
заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелгән ________________________________

______________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

___________________________________________ _____ елның «____»_________ № __________
Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ________________________________________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.
(вәкаләтле орган атамасы)

__________________ ____________ ________________________________________
(вазыйфа) (имза) (ФИА (соңгысы – булган очракта))

«_» _____20_ ел. Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

кемгә: Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына

кемнән: ________________________________________

(төзү, капиталь ремонтлау яки реконструкцияләүне гамәлгә ашырырга планлаштыра торган юридик зат – төзүченең атамасы;

________________________________________________

ИНН; юридик һәм почта адреслары; җитәкченең ФИА (соңгысы – булган очракта);

________________________________________________

телефон; банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

Техник хата төзәтү турында гариза

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә 20_____ елның ___________ № ____________________ рөхсәттә
(объектның атамасы)
түбәндәге адрестагы җир кишәрлегендә: _____________________________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)
техник хата җибәрелгән.

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәттә болай дип язылган _____________________________________________________________________________________
(кирәклесен язарга)

Түбәндәгеләргә нигезләнеп: ____________________________________________________________
(документның исеме һәм реквизитларын күрсәтергә)

дөрес язу _______________________________________________________________________________________
(кирәклесен язарга)

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп түбәндәгеләр хакында сорыйм:

1. Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә 20__ елның ___________ № ____ рөхсәттә җибәрелгән техник хатаны төзәтергә.

2. Югарыда күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен төзәтелгән рөхсәт бирергә.

Техник хатаны төзәтү өчен тапшырылган документлар һәм гаризада күрсәтелгән белешмәләр төгәл.

Техник хатаны төзәтү турында документларны кабул итү турындагы язуны алдым.

__________________ _____________ ____________________________________________
(вазыйфа) (имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

«_» _____20_ ел. Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Кемгә ___________________________________________
(юридик затның исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) - гражданнар һәм ШЭ өчен
_____________________________________________
почта индексы һәм адресы, электрон почта адресы)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

Дата ________________ № ____________

_________________ (мөрәҗәгать итүче) _____________ № _______ мөрәҗәгате нигезендә, _____________________________ бәйле рәвештә (баш тарту нигезе), дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Баш тарту сәбәбен дәлилле нигезләү: ___________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ___________________________ (баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту, баш тарту сәбәпләрен бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итү өчен каршылык булып тормый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

_______________________________________________________________ _________________________
(вазыйфа) (имза) (инициаллар)

«_» _____20_ ел. Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Автомобиль юлларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналы

| Тәртип саны | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы) | мөрәҗәгать итүче | Документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары | Объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны | объектны файдалануга кертүгә рөхсәт әзерләү датасы | Мөрәҗәгать итүчегә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт тапшыру датасы | Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт (объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |